| | |
|---|---|
| **ГЛАВА СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.11. 2020 ел. Иске Тәрбит авылы №3

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Иске Тәрбит авыл җирлеге
Иске Тәрбит авылында
үзара салым кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында .

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 28.07.2004 ел, № 45-ЗР Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп ярашлы рәвештә карар бирәм:

1. 2020 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка һәм 12 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы МФЦ бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар ике җыенның беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка һәм 12 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы МФЦ бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар ике җыенның икенче этабын билгеләргә.
3. 2020 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка һәм 12 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы МФЦ бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар ике җыенның өченче этабын билгеләргә.

2. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлегенен Янсуринское авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

а) *җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:
- урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

б) *җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру*:
- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;
- су башнясын лицензияләү буенча түләү(су белән тәэмин итү чыганагы буларак артскважинаны санитар-эпидемиологик бәяләмә һәм куллануга кирәкле башка документлар белән рәсмиләштерү).;

в) *җирлектәге торак пунктлар чикләрендәге җирле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге* ;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлектәге торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) *ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*
- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү,

“риза” “каршы”

6. Әлеге карарны Иске Тәрбит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Тәрбит авыл җирлеге башлыгы В.Г. Тимофеев